КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1011

«Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» акционерлар җәмгыяте һәм «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционерлар җәмгыяте акцияләрен Татарстан Республикасы милкенә кабул итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Суднолар төзелеше тармагын үстерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2018 ел, 24 август, 497 нче Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 ел, 27 сентябрь, б-2046 нчы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» акционерлар җәмгыятенең һәм «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционерлар җәмгыятенең федераль милектә булган акцияләре пакетларын шул ук эзлеклелектә 75 процент минус бер акция күләмендә (4 434 486 данә акция) һәм 11,9021 процент күләмендә (3 811 594 данә акция) Татарстан Республикасы милкенә кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән акцияләр пакетларын Татарстан Республикасы милкендә тапшырылган көннән биш ел эчендә саклауны;

б) бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән акцияләр пакетларын кире алу турындагы карарны, тапшырылган көннән биш ел үткәннән соң, бары Россия Федерациясе Хөкүмәте белән килештереп кенә кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, «Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» акционерлар җәмгыятенә һәм «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционерлар җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) әлеге акционерлар җәмгыятьләре эшчәнлегенең төп төрләрен саклауны;

б) 2023 елга кадәр «Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» акционерлар җәмгыятен һәм «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционерлар җәмгыятен комплекслы үстерүгә, шул исәптән аларның җитештерү куәтләрен модернизацияләүгә бу карарның 3 нче пунктындагы «в» пунктчада күздә тотылган килешү нигезендә шул ук эзлеклелектә кимендә 150 млн.сум һәм кимендә 300 млн.сум күләмендә инвестицияләр (шәхси инвесторлар акчасын кертеп) җәлеп итүне;

в) Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе, «Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» акционерлар җәмгыяте һәм «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционерлар җәмгыяте арасында, Татарстан Республикасы җәлеп итә торган инвестицияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган аларның фәнни-җитештерү потенциалын үстерү, кораблар һәм суднолар төзелеше проектларын тормышка ашыру буенча интеллектуаль, җитештерү һәм финанс ресурсларын туплау, җитештерү куәтләрен модернизацияләү чараларын күздә тотып, әлеге акционерлар җәмгыятьләрен үстерү турындагы килешү шартларын килештерүне.

4. Бу карарның 1 нче, 2 нче пунктлары үтәлешен тикшерүдә тотуны – Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, 3 нче пункты үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин